**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 44 15.11.2016 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Урсай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмләрне кертергә:

1.1. 7 нче статьяның 1 нче өлешен 14 нче пункт белән тулыландырырга:

«14) Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чаралар үткәрү».

3. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«10 нчы статья. Муниципаль хезмәтнең хокукый көйләве»

Муниципаль хезмәтне хокукый көйләү, муниципаль хезмәт вазифаларына таләпләр, муниципаль хезмәткәрнең статусын билгеләү, муниципаль хезмәтне үтү шартлары һәм тәртибе 2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законнары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы, әлеге Устав һәм башка муниципаль норматив хокукый актлар белән башкарыла.

Авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә социаль һәм башка гарантияләр бирү шартлары поселение муниципаль хокукый актлары белән билгеләнергә мөмкин.

1.3. 29 статьяда:

1.3.1. статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Депутат, җирле үзидарәнең сайланган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланган вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләүче башка зат, 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законы һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланган органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланган вазифаи затының, муниципаль вазифаны биләүче башка затның вәкаләтләре, 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законы, 2012 елның 3 декабрендәге № 230-ФЗ «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту

турында» Федераль законы, 2013 елның 7 маендагы № 79-ФЗ «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалану тыю турында» Федераль законы белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны үтәмәү очрагында вакытыннан алда туктатыла.».

1.3.2. 3 нче өлешне икенче-дүртенче абзацлар белән тулыландырырга:

«Авыл советы депутатлары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- Үз керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре, шулай ук үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итәргә.

- Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә, вазифа бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итәргә, бу кызыксыну конфликтка китерә яки китерергә мөмкин, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яки җайга салу өчен чаралар күрергә.

1.4. 47 нче статьяның 1 нче өлешенең 7 нче пунктын унберенче абзац белән түбәндәгечә тулыландырырга:

«- Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль закон белән каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чаралар үткәрә».

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А. Абдуллин